КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 апрель г.Казань № 543

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 май, 274 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсының конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» еллык республика конкурсын гамәлгә кую турында» 2017 ел, 11 май, 274 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 апрель, 328 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсының конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

конкурс комиссиясе составыннан А.Ә.Кәримовны, Ф.Г.Миңнегуловны, Р.К.Сабировны, А.П.Савельчевны, С.В.Юшконы чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, конкурс комиссиясе рәисе Олег Владимирович Коробченконы;

Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары Ренат Марат улы Галиевны (килешү буенча);

«Казан илкүләм тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Юрий Михайлович Казаковны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Марат Фәйзрахман улы Миңнебаевны;

«Сибур» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең тармак сатулары җитәкчесе Юлия Сергеевна Румянцеваны (килешү буенча);

Ирек Илдар улы Минсадыйровның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының химия һәм газ химиясе бүлеге башлыгы, конкурс комиссиясе секретаре»;

Айрат Фоат улы Сафинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Рафинат Самат улы Яруллинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин